**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.02.2020 № 21 од

г. Казань

Татарстан Республикасы Түбән Кама районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Түбән Кама районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/65 номерлы боерыгы белән расланган исемлеген тулыландыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама районы территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/65 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2017 елның 8 маендагы 01-02/43 номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәреш белән) расланган исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$1^{1}$ | «Кама Аланы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлеге | Татарстан Репубикасы, Түбән Кама районы, Кама Аланы шәһәр тибындагы бистәсе, М IV-14 | 14 мкр.4 бина янындагы территория, Җиңү монументы янында |
| | | Татарстан Репубикасы, Түбән Кама районы, Кама Аланы шәһәр тибындагы бистәсе, 4/01 йорт | 01 мкр.4 бина янындагы территория, «Чулман-Су» мәдәният үзәге янында |

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Татарстан Республикасының рәсми порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Р.И. Заһидуллин